**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Үчәлле авылы №110 17 сентябрь 2018 ел

Үчәлле авылы җирлеге биләмәсендә
үзара салым җыю һәм куллану буенча
җирле референдум үткәрү көнен
билгеләү турында.

2002 елның 12 июнендә кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре” турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 маддәсе, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның уртак принциплары” турындагы 131 номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән “Җирле референдум” турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законының 18 маддәсе, Үчәлле авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Үчәлле авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 3 сентябрендә чыккан 11 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары, Үчәлле авыл җирлеге Советының 2018 елның 3 сентябрендә чыккан 109 номерлы “Җирле референдум үткәрү” карары нигезләрендә,

**Үчәлле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. Үчәлле авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча **2018 елның 18 ноябрендә** референдум үткәрергә.

2. Референдумда караласы мәсьәлә:

**“Сез, Үчәлле авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2019 елда 300 сум күләмендә үзара салым җыю белән килешәсезме. Үзара салым түләүдән көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 группа инвалидлар азат ителә**.

Үзара салымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:

1. Җирлек территориясендә физик культура һәм спорт белән массакүләм шөгыльләнү өчен мөмкинлекләр тудыру:

-Спорт корылмаларын инвентарь белән тәэмин итү, спорт костюмнары сатып
алу.

2.Җирлек территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү:
-Янгын депосын тәэмин итү.
- Янгын куркынычсызлыгы инвентарьларе алу.
3. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм зияратларны карау:
-Зияратларда агачларны кисү өчен бензин пычкысы алу.
4.Авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү:
-Авыл җирлегенә караган авылларның юлларын кардан чистарту;
- Куакларны кисү, чүп үләннәрен чабу, аларга каршы химик эшкәртү уздыру.
- Урам утларын карау, лампаларны алмаштыру.
5. Бәйрәм чаралары уздыру:
- “Сабантуй”, “Халыкара өлкәннәр көне”,”Яңа ел” бәйрәмнәре уздыру өчен бүләкләр, сувенирлар алу.

**“ӘЙЕ”** **“ЮК”**

3. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.

4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Рәис Г.М. Төхвәтуллина